| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**Исполнительный комитет**<br>**Альметьевского сельского**<br>**поселения Сармановского**<br>**муниципального района** | **Татарстан Республикасы**<br>**Сарман муниципаль районы**<br>**Әлмәт авыл җирлеге**<br>**башкарма комитеты** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 31 январь № 1

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Әлмәт авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең « 2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. 2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча 6964,68 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2021 елның 29 гыйнварендәге 3 нче номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Д.Ә.Газизов

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2022 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карарына
1 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4011,67 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1448,65 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1504,36 |
| Барлыгы | 6964,68 |

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесенең
2022 елның 31 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
2 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе-(сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Кәфенләү | 1337,91 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2668,19 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1448,65 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1509,93 |
| Барлыгы | 6964,68 |